РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО
КОМИТЕТА
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЮГАРЫ ОСЛАН
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

26.04.2022 | с. Верхний Услон | №34

«Юл билгеләре кую турында» Югары Ослан авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2018 елның 8 февралендәге 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, "Юл хәрәкәте иминлеге турында" 1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы, "Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында" 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы федераль законнарга һәм "Татарстан Республикасында автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында" 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып,

КАРАР БИРӘМ:

1. Карарның 1 пунктын түбәндәге абзац белән тулыландырырга: «Парковка (парковка урыны)» 6.4 мәгълүмат билгесен һәм «Инвалидлар» 8.17. өстәмә мәгълүмат билгесен Район суды бинасы, Югары Ослан авылы, Совет урамы, 55 йорт янында урнаштырырга.
2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Югары Ослан Башкарма комитеты җитәкчесе Д.В.Котков